**ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШЕН КҮЗӘТҮ ИНСПЕКЦИЯСЕ**

№ 151 л/с

ПРИКАЗ БОЕРЫК

“ 15 “ август, 2013 ел

2011 елның 22 мартындагы “ТР ДТК Инспекциясендә ТР дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларын биләүгә конкурслар уздыру турындагы Нигезләмәне раслау турында”гы 42 л/с номерлы боерыкка үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә (алга таба - Инспекция) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларын биләүгә конкурслар үткәрү өлкәсендә норматив-хокукый көйләүне камилләштерү максатларында боерык бирәм:

1. 2011 елның 22 мартындагы “ТР ДТК Инспекциясендә ТР дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларын биләүгә конкурслар уздыру турындагы Нигезләмәне раслау турында”гы 42 л/с номерлы боерык (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2011 елның 16 июнендә теркәлгән, теркәлү номеры – 1252: “Татарстан Республикасы”, 5 июль, 2011 ел. № 133) белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурс үткәрү турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“18 яшькә җиткән, Россия Федерациясенең дәүләт телен белгән һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте турындагы законнарында каралган граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына карата тиешле квалификация таләпләренә җавап бирүче Россия Федерациясе гражданнары конкурста катнашу хокукына ия.

Конкурсны үткәрү вакытында нинди вазыйфаны биләвенә карамастан, граждан хезмәткәре гомуми шартларда конкурста катнашырга хокуклы”.

1.2. 1.5.1, 1.5.2 пунктларын алып ташларга.

1.3. 1.7 пунктының “в” пункт өлешен түбәндәге редакиядә бәян итәргә:

“2004 елның 27 июлендәге “Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында”гы 79-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясының 2 өлешендә, 31 статьясының 1 өлешендә һәм 60.1 статьясының 9 өлешендә каралган очракларда граждан хезмәткәрен граждан хезмәтенең башка төр вазыйфасына билгеләгәндә”;

1.4. 2.4 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

“Инспекциянең конкурс комиссиясе составына Инспекция каршында боерык нигезендә булдырылган Иҗтимагый совет әгъзалары кертелә”.

1.5. 2.7 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

“Конкурс комиссиясе утырышын бары тик аның дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалары катнашында гына үткәрү рөхсәт ителми”.

1.6. 3.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

“Конкурста катнашу теләген белдергән Инспекциядә дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләүче граждан хезмәткәре гаризаны Инспекция Башлыгы исеменә тапшыра.

Инспекциядә узучы конкурста катнашырга теләк белдергән башка дәүләт органында граждан хезмәте вазыйфасын биләүче граждан хезмәткәре Башлык

исеменә гариза һәм, фотосурәтен теркәп, расланган формада шәхсән үзе тарафыннан тутырылган, имзаланган һәм әлеге граждан хезмәткәре граждан хезмәте вазыйфасын биләгән дәүләт органының кадр хезмәте тарафыннан расланган  анкета тапшыра.

Инспекциядәге граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә дәгъва белдергән гражданин керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматларны, һәм шулай ук хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматларны тапшырырга бурычлы, әгәр дә гражданин яисә граждан хезмәткәре дәгъва кылган Татарстан Республикасы граждан хезмәте вазыйфасы, 2009 елның 30 декабрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматларны, һәм шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары, милек һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматларны тапшыруы турында”гы 702-ПУ номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, Инспекциянең 2013 елның 25 июнендәге “Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендәге, аларга билгеләнгәндә һәм аларны биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре, һәм шулай ук хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында белешмә бирү мәҗбүри булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында”гы 59 номерлы боерыгы белән расланган граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә кертелгән булса, конкурста катнашучы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматларны, һәм шулай ук хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре, чыгымнары, милке

һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматларны тапшырырга бурычлы”.

1.7. түбәндәге эчтәлекле 3.4 пункты белән тулыландырырга:

“Гражданин (граждан хезмәткәре), граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына карата квалификация таләпләренә туры килмәве сәбәпле, һәм шулай ук граждан хезмәтенә керү һәм аны үтү өчен дәүләт граждан хезмәте турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләмәләр нигезендә конкурста катнашуга кертелми.

Конкурста катнашуга кертелмәгән граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә дәгъва белдерүче претендент әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә кире караттырырга хокуклы”.

2. Юридик бүлеккә (Р.З. Фатыхов) әлеге боерыкны дәүләт теркәвен узу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башлык вазыйфаларын башкаручы Плюснин И.Н.